**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.12.2013 № 2498

**г. Казань**

Татарстан РеспубликасыСәламәтлек саклау
министрлыгының 2010 елның 14 январеннән булган
11нче боерыгына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 30 сентябреннәнбулган УП-636 номерлы«Коррупциягә каршы хәрәкәт турында»гы Федераль законныңаерымположениеләрен тормышка ашыру чаралары турында» Татарстан РеспубликасыПрезиденты Боерыгынүтәү максатында б о е р а м :

1. ТатарстанРеспубликасыСәламәтлек саклау министрлыгының 2010 елның 14 январеннән булган 11нче боерыгынатүбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нчепунктнытүбәндәге редакциядәязарга:

«3.Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгындаТатарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгать низагларын көйләү буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе рөхсәте белән, әгәр оешма белән дәүләт (административ) идарә итүнең аерым функцияләре Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфа (хезмәт) бурычларына кергән булсалар,Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Исемлеккә кертелгәнТатарстан Республикасыныңдәүләт граждан хезмәте вазыйфасын башкаргангражданин, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә хезмәт килешүе шартларында оешмадавазыйфаларны башкарырга һәм (яки) гражданлык-хокукый килешү (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларындабу оешмада бер ай эчендә йөз мең сумнан артык бәягә эшләр эшләргә (бу оешмага хезмәт күрсәтергә)хаклы.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасының Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын башкарган гражданин,дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел эчендә шушы боерыкның 3нче пунктының беренче абзацында күрсәтелгән эшләрне эшләүгә (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт килешүләренһәм гражданлык-хокукый килешүләрне төзегән очракта, эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиленә соңгы эш урыны турында хәбәр итәргәбурычлы.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасының Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын башкарган гражданинның, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң шушы боерыкның 3нче

пунктының икенче абзацы белән каралган таләпне үтәмәвешушы боерыкның 3нче пунктының беренче абзацында күрсәтелгән эшләрне эшләүгә (хезмәт күрсәтүгә) күрсәтелгән гражданин белән төзелгән хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүенең туктатылуынакитерә».

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләренәТатарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасыныңдәүләт граждан хезмәткәрләренкертелгән үзгәрешләр беләнтаныштырырга.

3. «ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 2010 елның 14 январеннән булган 11нче боерыгының кушымтасына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан РеспубликасыСәламәтлек саклау министрлыгының2010 елның 13 октябреннән булган 1294нче боерыгынкөчен югалткан дип танырга.

4. Боерыкның үтәлүен тикшерүнеүз өстемдә калдырам.

Министр А.Ю.Вафин